**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» июнь, 2026 ел № 425-п

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елның өченче кварталына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак Кодексы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТР номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан һәм салым салынырга тиешле граждан милкендә, күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыкның 2026 елның 16 февралендәге 57 номерлы хаты белән Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны наем шартнамәсе буенча Торак урын бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен максималь күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен-3 533 310,00 сум

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен-4 496 940,00 сум

1.1.1. Өч кешедән торган гаилә өчен-5 781 780,00 сум

1.1.2. Дүрт кешедән торган гаилә өчен-7 709 040,00 сум

1.1.3. Биш кешедән торган гаилә өчен-9 636 300,00 сум

1.1.4. Алты кешедән торган гаилә өчен-11 563 560,00 сум

1.1.5. Җиде кешедән торган гаилә өчен-13 490 820,00 сум

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен-46 295,99

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен-29 461,00 сум

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен-25 252,36 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне гражданнарны муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча исәпкә кую һәм аларга торак урыннары бирү максатларында аз керемлеләр дип тану өчен файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов